**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, поселогы,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 12.07.2022** **№ 690**

## «2022-2023 елларга Биектау муниципаль районының әйләнә-тирә мохитен саклау» муниципаль программасын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «2022-2023 елларга Биектау муниципаль районының әйләнә-тирә мохитен саклау» муниципаль программасын расларга.
2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «2022-2023 елларга Биектау муниципаль районының әйләнә-тирә мохитне саклау» муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 19 гыйнварындагы 96 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ф. Хәкимуллинга йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф. Хисамутдинов

Кушымта

Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның «12»07 №690 карары белән расланды

# «2022-2023 елларга БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘ МОХИТЕН САКЛАУ» МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ

**«2022-2023 елларга Биектау муниципаль районының әйләнә-тирә мохитен саклау» муниципаль программасының паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2022-2023 елларга Биектау муниципаль районының әйләнә-тирә мохитен саклау» муниципаль программасы. |
| Программаны эшләү өчен хокукый нигезләр | «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, ТР Экология кодексы. |
| Программаны төп эшләүчеләр | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты. |
| Программаны башкаручылар | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты, Биектау муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетлары, Биектау муниципаль районының муниципаль учреждениеләре, оешмалары һәм предприятиеләре |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | Программаның төп максатлары түбәндәгеләр:<br>- районда экологик һәм санитар-эпидемиологик хәлне саклауга һәм тотрыклылыгына юнәлдерелгән конкрет чараларны гамәлгә ашыру;<br>- табигать ресурсларын әйләнә-тирә мохит компонентлары буларак саклау һәм торгызу чараларын гамәлгә ашыру;<br>- хуҗалык эшчәнлегенең экологик иминлеген арттыру.<br>Программаның бурычлары түбәндәгеләр:<br>- корылмаларны һәм башка объектларны эксплуатацияләгәндә әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны киметү;<br>- техноген аварияләр килеп чыгу куркынычының минималь мөмкин булган дәрәҗәсен тәэмин итү;<br>- эпидемиологик иминлек дәрәҗәсен күтәрү;<br>- калдыкларны эшкәртү һәм утильләштерү системасын кертү;<br>- яшелләндерү һәм табигый ландшафтларны саклау аша район территориясендә экологик табигый каркас булдыру. |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары | 2022-2023 еллар |
| Программаны финанслауга ихтыяҗ күләме | Программаны финанслаукүләме – 6782,00 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2022 ел - җирле бюджет исәбеннән – 3391,00 мең сум;<br>2023 ел - җирле бюджет исәбеннән – 3391,00 мең сум. |
| Программаны | Экологик тәрбия һәм әйләнә-тирә мохитне саклауны, чүп-чарны |

| | |
|---|---|
| гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | аерым җыюны, табигать ресурсларын саклауны пропагандалау.<br>Корылмаларны һәм башка объектларны эксплуатацияләгәндә әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны киметү.<br>Гидротехник корылмаларны эксплуатацияләгәндә техноген аварияләр килеп чыгу куркынычының минималь мөмкин булган дәрәҗәсен тәэмин итү.<br>Үләксә базларының санитар-яклау зоналарын кыскартуны бәяләү юлы белән эпидемиологик иминлек дәрәҗәсен күтәрү;<br>Калдыкларны эшкәртү һәм утильләштерү системасын кертү;<br>Яшелләндерү һәм табигый ландшафтларны саклау аша район территориясендә экологик-табигый каркас булдыру. |
| Программаны үтәүгә контроль оештыру | Программаны гамәлгә ашыруны контрольдә тоту Биектау муниципаль районы башкарма комитеты һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы тарафыннан тормышка ашырыла. |

# Кереш

Әлеге Программа «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Экология кодексы нигезендә эшләнде.

Программа Биектау муниципаль районында экологик хәлне яхшыртуга юнәлтелгән чараларны үтәүгә бәйле муниципаль программаларны әзерләү һәм гамәлгә ашыру тәҗрибәсен исәпкә алып эшләнде.

Әлеге Программа Биектау муниципаль районы территориясенең төп экологик проблемаларын хәл итәргә ярдәм итүгә юнәлтелгән.

Программа әйләнә-тирә мохитнең сыйфатын яхшырту, территорияләр белән идарә итү системасын һәм хуҗалыкның аерым тармакларын камилләштерү, Биектау муниципаль районында хуҗалык эшчәнлегенең экологик куркынычсызлыгын арттыру нигезендә гражданнарның уңайлы яшәү шартларын булдыруга юнәлдерелгән.

Программаның төп юнәлешләре булып һава бассейнын, су ресурсларын саклау, җитештерү һәм куллану калдыкларын утильләштерү, табигать-экология кадастрын үстерү һәм биологик төрлелекне саклау чаралары тора.

## 1. Программаның максатлары һәм бурычлары

Программаның төп максатлары түбәндәгеләр:

1. районда экологик һәм эпидемиологик хәлне саклауга һәм тотрыклылыгына юнәлдерелгән конкрет чараларны гамәлгә ашыру;
2. табигать ресурсларын әйләнә-тирә мохит компонентлары буларак саклау һәм торгызу чараларын гамәлгә ашыру;
3. хуҗалык эшчәнлегенең экологик иминлеген арттыру.

Программаның бурычлары түбәндәгеләр:

1. корылмаларны һәм башка объектларны эксплуатацияләгәндә әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны киметү;
2. техноген аварияләр килеп чыгу куркынычының минималь мөмкин булган дәрәҗәсен тәэмин итү;
3. эпидемиологик иминлек дәрәҗәсен күтәрү;
4. калдыкларны эшкәртү һәм утильләштерү системасын кертү;
5. яшелләндерү һәм табигый ландшафтларны саклау аша район территориясендә экологик табигый каркас булдыру.

## 2. Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары

Программаны гамәлгә ашыру сроклары 2022 – 2023 еллар.

Корылмаларны һәм башка объектларны эксплуатацияләгәндә әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны киметү; гидротехник корылмаларны эксплуатацияләгәндә техноген аварияләр килеп чыгу куркынычының минималь мөмкин булган дәрәҗәсен тәэмин итү; үләксә базларының санитар-яклау зоналарын кыскартуны бәяләү юлы белән эпидемиологик иминлек дәрәҗәсен күтәрү; калдыкларны эшкәртү һәм утильләштерү системасын кертү; яшелләндерү һәм табигый ландшафтларны саклау аша район территориясендә экологик-табигый каркас булдыру буенча чаралар тормышка ашырылачак.

## 3. Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары

Программаны финанслау күләме 6782,00 мең сум тәшкил итә.

Программаны үтәү Биектау муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән һәм оешмаларның, предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең үз акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

**Программаны финанслау структурасы**

мең сум

| Финанслау чыганаклары | Барлыгы | Шул исәптән еллар буенча | |
|---|---|---|---|
| | | 2022 ел | 2023 ел |
| Биектау муниципаль районы бюджеты | 6782,00 | 3391,00 | 3391,00 |
| Барлыгы: | 6782,00 | 3391,00 | 3391,00 |

Программа чаралары исемлеге һәм көтелгән нәтиҗәләр Программаның Кушымтасында тәкъдим ителде.

## 4. Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру

Программаны гамәлгә ашыруның барышын контрольдә тоту Биектау муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының һәм Биектау муниципаль районы башкарма комитетының агымдагы финанс елына табигатьне саклау чараларын үтәүне тәэмин итү буенча үзара хезмәттәшлеге турында төзелә торган еллык килешүләр кысаларында Биектау муниципаль районы бюджеты, Биектау муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан табигатьне саклау чараларын гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгына ай саен хисап җибәрелә.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 12.07.2022 690 номерлы карары белән расланган Программасына 1 нче кушымта

**«2022-2024 елларга Биектау муниципаль районының әйләнә-тирә мохитен саклау» программасы**

| № т/б | Чараның исеме | Срок лары | Эшләрнең гомуми бәясе, мең сум | Елларга бүлеп финанслау күләме, мең сум | | Финанслау чыганаклары | Башкаручылар | Көтелгән нәтиҗәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2022 | 2023 | | | |
| 1 | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының авыл җирлекләре территориясендә контейнер мәйданчыкларын төзү | 2022 | 2391,00 | 2391,00 | - | Биектау муниципаль районы бюджеты | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты | Санитар-эпидемиологик вәзгыятьне яхшырту, әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны киметү |
| 2 | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерү | 2022 | 2000,00 | 1000,00 | 1000,00 | Биектау муниципаль районы бюджеты | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты | Санитар-эпидемиологик вәзгыятьне яхшырту, әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны киметү |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 | Биектау муниципаль районы Олы Битаман авылындагы себер түләмәсе үләксә базының санитар-яклау зонасын кыскарту чаралары | 2023 | 2391,00 | - | 2391,00 | Биектау муниципаль районы бюджеты | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты | Санитар-эпидемиологик вәзгыятьне яхшырту, себер түләмәсенең санитар-яклау зонасын кыскарту |
| 4 | Ел саен экологик икеайлык үткәрү | 2022-2023 | - | - | - | Оешмаларның, предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең үз акчалары. | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты, Биектау муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетлары, Биектау муниципаль районының муниципаль учреждениеләре, оешмалары һәм предприятиеләре | Калдыкларны эшкәртү һәм утильләштерү системасын кертү; Яшелләндерү һәм табигый ландшафтларны саклау аша район территориясендә экологик-табигый каркас булдыру. |
| 6 | Мәктәп укучылары арасында экологик тәрбия дәресләре һәм экология олимпиадалары үткәрү | 2022-2023 | - | - | - | Учреждениенең үз чаралары | «Мәгариф бүлеге» МКУ | Экологик тәрбия һәм әйләнә-тирә мохитне саклауны, чүп-чарны аерым җыюны, табигать ресурсларын саклауны пропагандалау |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 7 | «Урман атнасы», «Агач утырт», «Агачларны бергә утыртыйк» экологик акцияләре кысаларында агачлар утырту һәм урманнарны чистарту | 2022-2023 | - | - | - | Учреждениенең үз чаралары | «ШӘһәр яны урманчылыгы» ДБУ | Яшелләндерү һәм табигый ландшафтларны саклау аша район территориясендә экологик-табигый каркас булдыру |
| 8 | Предприятиеләр буенча санитар-яклау зонасын (СЗЗ) оештыру проектларын эшләү һәм СЗЗ оештыру һәм төзекләндерү чараларын үтәү | 2022-2023 | - | - | - | Оешмаларның һәм предприятиеләрнең үз акчалары. | Биектау муниципаль районының оешмалары һәм предприятиеләре | Корылмаларны һәм башка объектларны эксплуатацияләгәндә әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны киметү. |
| | **БАРЛЫГЫ** | | **6782,00** | **3391,00** | **3391,00** | | | |